Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Түбән Мактама бистә башкарма комитеты

КАРАР

19 февраль 2026 ел №2

Әлмәт муниципаль районы «Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе» муниципаль берәмлеге территориясендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләү турында

«Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы, федераль закон, «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында»Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Берләшкән социаль фондының Әлмәт районындагы Клиент хезмәтенең (бүлек хокукларында) 2026 елның 262 гыйнварындагы 51-34-09/131 номерлы мөрәҗәгате нигезендә

Түбән Мактама бистә башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. № 1 нче, № 2 нче кушымталар нигезендә Әлмәт муниципаль районы «Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе» муниципаль берәмлеге территориясендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 9678,63 сум күләмендә билгеләргә.

2.Әлмәт муниципаль районының Түбән Мактама бистә башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе» муниципаль берәмлеге территориясендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләү турында» 2025 елның 5 февралендәге 2 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны торак пункт территориясендә Әлмәт районы, Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе, Некрасов урамы, 18А йорт, 30А йорт, Заводская урамы, 2А йорт, Достоевского урамы, 10 йорт, Х.Атласи урамы, 1А йорт һәм Тихоновка авылы, Терешковой урамы, 34А адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка игълан итәргә; «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2026 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Түбән Мактама бистә башкарма комитеты
җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Г.Ф. Баерова

Әлмәт муниципаль районы
Түбән Мактама бистә башкарма
комитетының 2026 елның
19 февралендәге 2 номерлы
карарына 1 нче кушымта

Әлмәт муниципаль районы «Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе» муниципаль берәмлеге территориясендә җирләү буенча гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе

| №№ п/п | Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе, сум. |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2 | Мәет җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 5 635,82 |
| 3 | Мәетнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка алып бару | 908,43 |
| 4 | Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3 134,38 |
| Барлыгы | | 9 678,63 |

Түбән Мактама бистә башкарма комитеты
җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Г.Ф. Баерова

Әлмәт муниципаль районы
Түбән Мактама бистә башкарма
комитетының 2026 елның
19 февралендәге 2 номерлы
карарына 2 нче кушымта

Әлмәт муниципаль районы «Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе»
муниципаль берәмлеге территориясендә
җирләү буенча гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган
хезмәтләрнең бәясе

| №№ п/п | Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе, сум. |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2 | Мәетне кәфенләү | 3 304,27 |
| 3 | Мәет җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2 331,54 |
| 4 | Мәетнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка алып бару | 908,44 |
| 5 | Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3134,38 |
| Барлыгы | | 9 678,63 |

Түбән Мактама бистә башкарма комитеты
җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Г.Ф. Баерова